Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авылы җирлегенең Татар Баганалысы авылы торак пунктында гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге составына керүче Татар Баганалысы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

КАРАР

2019 елның 15 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 15 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән, I төркем инвалидлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Татар Баганалысы авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм вак таш салу) ;

- урам утларын карап тоту (Татар Баганалысы авылында урамнарны яктырту яктырткычларын энергия саклаучы светодиод яктырткычларга алыштыру).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 434 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 239 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 239 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән,80 яшьтән өлкәнрәклә рдән һәм I төркем инвалидларыннан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- Татар Баганалысы авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм вак таш салу) ;

- урам утларын карап тоту (Татар Баганалысы авылында урамнарны яктырту яктырткычларын энергия саклаучы светодиод яктырткычларга алыштыру) буенча кабул ителде дип танырга.

3. Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Татар Баганалысы авыл җирлегенең Татар Баганалысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән, I төркем инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Татар Баганалысы авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм ташу, грунтлау һәм вак таш салу) ;

- урам утларын карап тоту (Татар Баганалысы авылында урамнарны яктырту яктырткычларын энергия саклаучы светодиод яктырткычларга алыштыру).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Баганалысы
авыл җирлеге башлыгы ________________ Р.Р.Җәббаров